

Зубово-Поляна районы Горенка авыл жирлеге мәдәни-ял итv vзәге китап-ханәчесе Румия Абдулла кызы Деликамова Горенка авылы китапханәсе сайтында болай яза. Кешелек доньясы һәрвакыт матурлыкка омтылып яшәгән. Гvзәллек белән янәшә vзен дә шәфкатьлерәк, мәрхәмәтлерәк булырга тырышасын. Безнен әби-бабаларыбыз элек-электән матурлыкка омтылганнар. Халкы-бызнын кvнел нурын сибеп чиккән сол-геләре, бизәкләп тукыган ашъяулыклары, чаршаулары... Инде 15 яшькә житкән кыз бала vзенә бизәкләп чигеп эшләнгән бирнә хәзерләгән. Кулланылышына карап (кvлмәк, алъяпкыч, сарафан, солге-тастымал, эскәтер һ.б.), һәр әйбер vзенә генә хас декоратив бизәкләр белән чигелгән.       Гасырлар буе һәр халык vзенчәлекле чигеш алымнарын, колоритын (тосләр балкышын) һәм орнаментларын булдырган. Элекке заманда татар ойләренен һәммәсендә намазлык, ойне икегә бvлеп торучы чаршау, сабый бишегенә тартылган чигvле чыбылдык, чигvле тәрәзә пәрдәләре, кашагалар, мендәр тышлары, жәймәләр... Йорәк хисләрен кушып, кvз явын алырдай бизәкләр тошереп чиккән, вәгъдә билгесе - кулъяулыклар булган. Бу - халкымнын кvнел байлыгы, анын рухи хәзинәсе. Ерак заманда татар авылларында кызлар vзләре очен бирнә әзерләгәннәр; аларны каюлап, укалап, тамбурлап, шома (тутырып чигv), крестиклап чиккәннәр.

1960-70 елларда безнен яраткан әниебез, Разия Насыйп кызы Хайрова (рә-семдә) һәм анын кечкенә сенелләре Райся, Алия һәм Ания япь-яшь кызлар, 15-20 яшьләренә кадәр Пенза олкәсе Шемышейка районы Усть-Уза авылында яшәгәннәр. Темников һәм Саранскидан килгән йомышлы (служилые) татарлар тарафыннан 1683 елда нигезләнгән бу авыл. Усть-Уза ярларын Сура сусаклагычы белән юыла.

Авылларда, элек-электән, эш кайнап торган. Кичке якка гына тәмамлана торган булган. Ә тәмамлангач, алар башка кызлар белән бергә, берәрсенен оендә жыелып татар халык жырларын бергәләп жырлый-жырлый, vзләренә бирнә әзерләгәннәр: солгеләр, яулык-лар, алъяпкычлар, мендәр тышлары... Бу кул эшләре безнен коннәргә кадәр могжизалы рәвештә сакланып калган.

Бездә шома чигv vрнәгендә салфеткалар саклана. Алар остәлгә ябып куяр очен бик

матур, хәтта матурлык очен стенага да элеп куйганнар. Тегv машинасында чигелгән салфеткалар да бар. Крестиклап чиккән солгеләрне стена сәгатьләренә, фотолар белән фото рамнарына элеп куйганнар. Әнием белән апаларым vз куллары белән тигез чигv белән чиккән алъяпкычлары бvген дә сакланган: аларга 50-60



ел инде. Әниебез Разия Насыйп кызынын кул эшләре һәм минем, Румия Абдулла кызынын vз кулларым белән чиккән әйберләребезне истәлек итеп кадерләп саклыйбыз. Олы улымны тудыргач, больницадан алып кайту очен, алдан ук чиккән уголок-очпочмак әзерләп куйган идем. Аны да кадерләп саклыйм.
Бу кыйммәтле мирас, хезмәт һәм матурлык очен әти-әниләребезгә, әби-бабаларыбызга рәхмәт. Алар саклый алганнары һәм безгә vз кулларынын осталыгын тапшыра алганнары очен рәхмәт!

**Н.ХӘЛИЛ әзерләде**